ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

04.12.2024 с. Куралово 03-10/54

Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге Уставы нигезендә, Куралово авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыенында кабул ителгән 2024 елның 26 ноябрендәге 3 номерлы һәм 2024 елның 30 ноябрендәге 4 номерлы карарларны гамәлгә ашыру максатларында Куралово авыл җирлегенең Башкарма комитеты карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Куралово авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Т. Ю. Тимиряева

Куралово авыл җирлеге
Башкарма комитетының
04.12.2024 ел 03-10/54
номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 мартына кадәр 18 яшькә җиткән, Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, түләнә.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) 1 төркем инвалидлар

б) мобилизацияләнгән гражданнар, контрактчылар һәм аларның гаилә әгъзалары

4. Түләүләр күләме гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:

а) күпбалалы гаиләләр,

б) уку йортлары студентлары,

в) тыл хезмәтчәннәре

5. Бер мәртәбә бирелә торган түләүне түләү турында хәбәрнамә (хәбәр итү) бланкы почта элемтәсе аша юллама бирү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/. сылтама буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

8. Түләү фактын раслау булып керем касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

9. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә

Югары Ослан
муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге
Башкарма комитетының
04.12.2024 ел 03-10/54
номерлы карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________
Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф. И.А.и.
________________________________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________
__________________________________________________________ нигезендә
Сезгә _______________________ вакытына кадәр
___________________________________________________ чараларны тормышка ашыру өчен _____________ сум күләмендә,
түбәндәге реквизитлар буенча:
__________________________________________________ бер тапкыр акча түләргә кирәк.
Алучының банк БИК _____________________________________
Сч. № _________________________________
Алучының сч. №__ . _________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _______________ ОКАТО__________________
Түләүне билгеләү
_____________________________________________________________________

Җитәкче _________________ _______________________________________
М. у. (имза) (имзаны киңәйтеп язу)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ______________________
(муниципаль берәмлек исеме)
________________ сум күләмендә.
Түләүченең Ф. И.А.и. ______________________________________________________
Адрес:
________________________________________________________________________
Алдым «__» _________________ 20___ ел. _____________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Әгәр дә хәбәр түләүчегә шәхсән бирелсә, аермалы төпсәсе тутырыла һәм _______________ авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*